РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ БИЗЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

03.03.2023 ел N 7

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының «Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе хакында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге № 414-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының " Бәзәкә авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының « Бәзәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр бирү тәртибе хакында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 18 июнендәге 14 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 статьясында 2 пунктта һәм 4 пунктта, 3 статьяның 1 пунктында “Татарстан Республикасы Президентына” сүзен “Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) сүзләренә алмаштырырга.
1.2. Нигезләмәнең 4 статьясында 2 пунктта “Татарстан Республикасы Президенты белән” сүзен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) белән сүзләренә алмаштырырга.
1.3. Нигезләмәнең 4 статьясында 4 пунктта “Татарстан Республикасы Президенты” сүзен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) сүзләренә алмаштырырга.
1.4 Нигезләмәнең 4 статьясы 2 пунктның 6 абзацында “Татарстан Республикасы Президентына” сүзен “Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бәзәкә авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылык, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын үтәүне тикшерү комиссиясенә йөкләргә.

Бәзәкә авыл җирлеге Советы рәисе И.И. Кәшәфетдинов